**Җәмгыять белеме буенча олимпиада**

**8-9 нче сыйныфлар.**

**Биремнәрне үтәү өчен 3 сәгать вакыт бирелә.**

**Эш вакыты – 180 мин**

**1. Сорауларга җавап бирегез. Әгәр сезнең җавабыгыз түбәндәге гыйбарә белән туры килсә “әйе”, туры килмәгәндә “юк” дип билгеләгез.**

1.1. Кешенең социаль асылы белән аның ихтыяҗлары үз-үзеңне танып белүгә бәйләнгән?

1.2. РФ Федераль Җыелышы гражданлык җәмгыяте институты булып тора.

1.3. Социаль төркем буларак гаилә дөньяга карашларының уртаклыгы белән характерлана.

1.4. Хәзерге Россия Федерациясендә башкаручы хакимиятнең югары органы булып Дәүләт Думасы тора.

1.5. Россия Федерациясе конституциясе 1992 елның 12 декабрендә кабул ителде.

1.6. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне хакимият тарафыннан җайга салуны политология фәне өйрәнә.

1.7. Хокукый дәүләткә хас булган төп билге булып хакимиятнең тармакларга бүленүе тора.

1.8. Татарстан Республикасының вәкаләтле һәм закон чыгаручы органы булып ТР Дәүләт Советы тора.

**Җавап:**

| 1.1 | 1.2 | 1.3 | 1.4 | 1.5 | 1.6 | 1.7 | 1.8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

**2. Сорауларга җавап бирегез. Дөрес җавап астына сызып куегыз.**

2.1. Законнарда һәм дәүләтнең башка актларында чагылыш тапкан, дәүләт тарафыннан саклanучы гомуммәҗбүри тәртип кагыйдәләре ничек атала ?

1) әхлак нормалары

2) хокук нормалары

3) партия нормалары

4) гадәти, традицион нормалар

2.2. Түбәндәге атамаларның кайсысы дәүләт белән идарә итү формасын аңлата?

1) федерация

2) республика

3) диктатура

4) автономия

2.3. Гражданин С. берничә ел дәвамында алимент түләүдән качып йөри. Гражданин С. эшен судка тапшыру өчен нинди хокук нормалары нигез булып тора?

1) хезмәт кодексы

2) гражданлык кодексы

3) гаилә кодексы

4) җинаять кодексы

2.4. “Король патшалык итә, әмма идарә итми”, - дигән танылган афоризм идарә итүнең нинди формасын тасвирлый?

1) абсолют монархияне

2) парламентар (конституцион) монархияне

3) парламент республикасын

4) Президент республикасын

2.5. Кабиләләр һәм халык – нәрсә ул?

1) этник уртаклык

2) җәмгыятнең тарихи типлары

3) социаль страталар

4) демографик төркемнәр

2.6. Җир эшкәртүче җирне махсус техника белән эшкәртә. Әлеге эшчәнлекнең субъекты булып нәрсә тора?

1) җир

2) техника

3) үстерелә торган культура

4) җир хуҗасы

2.7. Темперамент турындагы тәгълиматка кем нигез салган?

1) Сократ

2) Платон

3) Гиппократ

4) Әбүгалисина

**3. Рәттәге артык элементның астына сызыгыз һәм аңлатыгыз.**

3.1. Вексель, акциз, чек, акция, облигация.

______________________________________________________________________

3.2. Компаниянең җаны (Душа компании), интриган, җинаятьче, яла ягучы (ябеда).

______________________________________________________________________

3.3. Анимизм, синтоизм, фетишизм, тотемизм.

______________________________________________________________________

**4. Төшерелеп калдырылган урыннарны тутырыгыз**.

4.1. Җитештерү, алыштыру, бүлү, _____________.

4.2. Зур булмаган җинаять ике елга хәтле иректән мәхрум итү, уртача авыр җинаять 5 елдан артык булмаган срок, авыр җинаять ______ елга кадәр, бик авыр җинаять ____ елдан артык.

4.3. Торакка хокук - ул социаль хокук; митинглар, демонстрацияләр уздыру - ул сәяси хокук; дин тоту яки тотмау хокукы - ул __________________.

**5. Курсив белән билгеләнгән урыннарны җәмгыять белеме атамасы белән алыштырыгыз**.

5.1. Соңгы вакытларда күп милләтләр арасында үз туган телләренә игътибар киму, башка милләт вәкилләре белән никахка керү *этник йотылу* процессларын көчәйте.

Җавап: ______________________

5.2. Бүгенге көндә Европа илләрендә бара торган *күпсанлы кешеләрнең күченеп килүе* процесслары хакимият белән беррәттән төп халыкны да әлеге сәясәт өлкәсендә яңа үзгәрешләр кертүгә этәрде.

Җавап: ______________________

5.3. Европа һәм АКШ тарафыннан каралган санкцияләр Россиядәге *икътисад тармакларына кертелгән капиталларның* күләмен шактый киметте.

Җавап: ______________________

**6. Лингвистик конструктор. Китерелгән сүзләрдән төшенчәнең билгеләмәсен төзегез һәм язып куегыз. Түбәндә сүз алып барыла торган төшенчәне атагыз.**

6.1. Буенча, гражданы, үз теләге, затның, яки, нинди дә булса, итеп, подданные, ил, кабул итүе

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

6.2. Реаль акча, алтын, әйләнеш сферасында, белән чагыштырганда, кәгазь акчаның, кирәгеннән, артып китүе, чыгарылган, артык күп итеп

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

**7. Беренче баганада бирелгән һәр төшенчәгә икенче баганадан туры килә торган аңлатманы сайлап алыгыз.**

1) Эмоцияләр

2) хисләр

3) фикерләр

4) инстинкт

5) аффект

А) кешенең тумыштан килгән психик һәм үз-үзенне тоту элементлары

Б) ситуацияләр һәм вакыйгалар өчен кайгырту

В) кайгыртуның иң югары формасы

Г) үз-үзенне һәм дөньяны аңлауның чагылышы

Д) кыска вакытлы көчле эмоциональ реакция

| 1. | 2. | 3. | 4. | 5. |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

**8. Түбәндәге ситуацияләрне хокук нормалары күзлегеннән чыгып анализлагыз.**

**8.1.** 16 яшьлек яшьүсмер эшкә урнашу теләге белән машиналар төзәтү остаханәсенә килә. Үзе белән ул паспорт, хәрби теркәлү турындагы таныклык һәм эшкә урнашу гаризасын алып килә. Ләкин остаханә хуҗасы медицина тикшерүеннән һәм тиешле справкадан башка аның белән килешү төзү хокуклыгы булмавын белдерде.

**Бу очракта остаханә хуҗасы хокуклымы? Үз җавабыгызны аңлатыгыз.**

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

__________________________________________________

8.2. Гражданка Зарипова аптекадан әнисенә дару сатып ала. Тукталышка барган вакытта әнисе аңа дару исемен бутаганы һәм башка дару кирәклеге турында телефоннан шалтыратып әйтә. Гарипова касса чегын алып,

даруларны алыштыру теләге белән аптекага кире әйләнеп кайта. Әмма сатучы әлеге төр товарны алыштыру мөмкин булмаганлыгын искәртә. **Бу очракта Зарипованың үтенече кире кагылуы хокуклымы? Үз җавабыгызны аңлатыгыз.**

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

**9. Түбәндә китерелгән исемлектә кешенең социаль статуска ирешүенә мөнәсәбәте булган факторларны һәм аларга туры килгән саннарны билгеләгез.**

1) социаль чыгышы

2) һөнәре

3) яше

4) табыш (керем) дәрәҗәсе

5) җенесе

6) белеме

Җавап: ____________________

**10. Фәннәр һәм аларның кыскача аңлатмалары арасында тәңгәллекне билгеләгез. Игътибар итегез: аңлатмалар фәннәргә караганда артыграк.**

| *Фән* | *Кыскача аңлатма* |
|---|---|
| 1. Антропология<br>2. Педагогика<br>3. Психология<br>4. Социология<br>5. Политология | *А.* Тәрбия һәм укыту турындагы фән<br>*Б.* Җәмгыять һәм иҗтимагый бәйләнешләр турындагы фән<br>*В.* Кешенең биологик табигате турындагы фән<br>*Г.* Кешенең психик эшчәнлеге турындагы фән<br>*Д.* Организмнарның фунцияләре һәм агуланулары турындагы фән |

| | |
|---|---|
| | Е. Хакимият, дәүләт бәйләнешләрен өйрәнүче фән |

Җавап:

| 1. | 2. | 3. | 4. | 5. |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

**11. Татарстан Республикасының Дәүләт Конституциясе 7 бүлектән тора. Әлеге бүлекләрне хронологик тәртиптә урнаштырыгыз.**

1) Дәүләт хакимияте оештыру.

2) Конституцион тәзелеш нигезләре

3) Кеше һәм гражданнарның төп хокуклары, ирекләре һәм бурычлары

4) Җирле үзидарә


5) Административ-территориаль төзелеш

6) Дәүләт символлары һәм Татарстан Республикасы башкаласы


7) Татарстан Республика Конституциясен кабул итү тәртибе һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү

Җавап: ______________________________

**12. Схемада төшереп калдырылган сүзне язып куегыз.**




Җавап: _____________________




Җавап: ____________________

**13. Икътисади система төрләре һәм аларны характерлаучы үзенчәлекләр арасында тәңгәллекне ачыклагыз. Беренче баганадан бирелгән үзенчәлекләргә туры килә торган төшенчәне икенче баганадан сайлап алыгыз.**

| **Характерлы үзенчәлекләр** | **Икүтисади система төрләре** |
|---|---|
| А) дәүләт милкенең өстенлеге<br>Ә) бәяләр билгеләп куюның ирекле булуы<br>Б) җитештерү һәм аны бүлгәләү өстеннән дәүләт күзәтчелеге<br>В) эшләп чыгаручыларның икътисади мөстәкыйльлеге<br>Г) конкурентлык | 1) административ-команда<br>2) базар |

Сайлап алынган саннарны таблицага язып куегыз.

| А | Ә | Б | В | Г |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

**14. Түбәндә китерелгән текстны укып чыгыгыз, анда кайбер сүзләр төшереп калдырылган. Тәкъдим ителгән исемлектән сүзләрне буш калган урыннарга язып куярга кирәк.**

«Галимнәр диннәрнең берничә классификациясен эшләделәр. Аларның иң гадие диннәрне өч төркемгә берләштерү. Примитив ыру-кабилә ышанулары, мәсәлән, __________(1). Алар __________(2) барлыкка килде, ләкин вакытлар

узу белән кешеләр аңыннан юкка чыкмадылар, ә сакланып калдылар һәм бүгенгәчә катлаулырак диннәр белән бергә яшиләр. Аларда күпсанлы__________(3) бар. Аерым милләт-дәүләтнең бөтен яшәешенең асылы булган милли-дәүләт диннәре бар, мәсәлән _________(4). Милли-дәүләт чикләрен үтеп чыгучы һәм бөтен дөньяда күпсанлы тарафдарлары булган дөнья диннәре, дөньяда алар өчәү: ____________(5), христиан дине һәм ислам. Барлык диннәрне ике зур төркемгә берләштерергә була:_____________(6), ягъни Аллаһның берлеген танучылар, һәм _____________(7) күп аллаларны танучылар.

Исемлектәге сүзләр баш килештә, берлек санда бирелгән. Сүзләрне, бушлыкны тутырып, бер-бер артлы сайлап алыгыз. Китерелгән исемлектә сүзләрнең текстка төшерелгәннәрдән күбрәк булуына игътибар итегез.

А) монотеизм
Ә) политеизм
Б) борынгы
В) культ
Г) буддизм
Д) индуизм
Е) хорафат, юк-барга ышану
Ж) миф
З) православие
И) тотемизм

**Түбәндәге таблицада бушлыкларның саннары күрсәтелгән. Һәр сан астына үзегез сайлап алган сүзләргә туры килгән хәрефләрне язып куегыз.**

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

**15. Сезнең алдыгызда таблица. Беренче баганада латин яисә грек төшенчәләрнең турыдан-туры тәрҗемәсе. Икенче баганада әлеге төшенчәләр белән бәйләнгән иҗтимагый күренешләр күрсәтелгән. Таблицага төшенчәләрне һәм аларның мәгънәсен язып тутырып бетерегез.**

| Латин яисә грек төшенчәсенең тәрҗемәсе | Иҗтимагый күренешләр | Төшенчәләр һәм аларның мәгънәсе |
|---|---|---|
| «Сабырлык, түземлек» | Социаль мөнәсәбәтләр | |

| | | |
|---|---|---|
| «Җайлашу» | Социальләшү | |
| “Халәт, хәл” | Иҗтимагый мөнәсәбәтләр | |
| «Таратылырга тиешле” | Идеология | |
| “Аерым” | Милли мөнәсәбәтләр | |
| “Ул да түгел, башка да түгел” | Дәүләтнең тышкы сәясәте | |

**16. Түбәндә тәкъдим ителгән өземтәләрнең <u>берсен</u> сайлап алыгыз һәм күтәрелгән мәсьәлә буенча үз фикерегезне (карашыгызны, мөнәсәбәтегезне) бәян итегез. Үз карашыгызны нигезләү өчен <u>дәлилләр</u> китерегез.**

**Биремне үтәгәндә җәмгыять белеме курсыннан алган белемнәрегезне, туры килгән төшенчәләрне, шулай ук иҗтимагый тормыш фактларыннан һәм үз тормыш тәҗрибәгездән файдаланыгыз.**

**Темалар:**

1) «Кешегә рухи зат буларак, Җирдә хокуктан тыш яшәү мөмкин түгел» (И.А. Ильин).

2) «Фәлсәфә - ул чишеп булмастай мәсьәләләргә аз аңлаешлы җаваплар бирү» (Г.Б. Адамс).

3) «Кем вәгъдә биргәндә сак эш итә, аны үтәвен дә төгәл үти» (Ң.Ң.Руссо).

4) «Сәүдәнең бер генә халыкны да бөлгенлеккә төшергәне юк әле» (Б.Франклин).

5) «Матурлык күп көч түгеп өйрәнгәннән соң гына, ә начарлык көч түкмичә, үзеннән-үзе дә өйрәнелә» (Демокрит).

6) «Камиллектән курыкма, син аңа беркайчан да ирешә алмаячаксың» (С.Дали).